**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Каргалы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**27 ноябрь, 2024 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 27 нче ноябрендә 10сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге территориясенә кергән Каргала авылыда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм 2025 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 41 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 28 кеше, бу 68,3% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 28 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргалы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Каргалы авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (бишйөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М.Емельянова